**СОВЕТ**
**Кудашевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кодаш авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.10.2023. Кодаш авылы № 30-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегенең генераль планын әзерләү кирәклеге булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясен куллануны үзгәртү күздә тотылмавына бәйле, социаль-икътисадый үсешнең расланган программасы булмау,Татарстан Республикасын һәм Әгерҗе муниципаль районын территориаль планлаштыру схемаларында федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру каралмаганга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегенең генераль планын эшләүдә ихтыяҗ булмавын 2023 елның «30» декабренә кадәр танырга.

2.Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның «1» гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы порталы составында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе .М.ШАКИРОВ

Совет Кудашевского сельского поселения Кодаш авыл җирлеге Советы ИНН 1601002501
Агрызский муниципальный район Республики Татарстан Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы